КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 29 март г.Казань № б-694

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 август, б-1684 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 ноябрь, б-2363 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2032 елларда Татарстан Республикасында Халыкара җирле халыклар телләре унъеллыгына багышланган чараларны үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан М.Х.Сәлаховны, Т.Д.Сөләймановны, И.И.Шәриповны, К.Г.Яковлевны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Әхмәдиев Роза Шәйхәйдәр кызын | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |
| Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын | Татарстан халыклары ассамблеясе Советы башкарма комитеты җитәкчесен – Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасарын (килешү буенча) |
| Кадыйров Тимур Рәфкать улын | «Татарстан халыклары дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директорын |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улын | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президентын |
| Садыйков Ринат Наил улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын; |

Руслан Роберт улы Мөхәррләмовның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин